РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск,
423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 15 октябре № 13

Түләнеп бетмәгән салымны, җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2019 елның 2 апрелендәге ММВ-7-8/164@ номерлы «Түләттерү өметсез дип танылган пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча түләнеп бетмәгән салымны һәм бурычларны исәптән чыгару тәртибен һәм түләнеп бетмәгән салым, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» боерыгы, Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түләнеп бетмәгән салымны, җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә (алга таба - бурыч):

-варисларның мирас хокукыннан баш тарткан яки вафат булу датасыннан 6 ай эчендә мираска хокуклары турында игълан итмәгән очракта, вафат булган яки вафат булды дип игълан ителгән физик затларның җир салымы һәм милеккә салым буенча, әгәр бурыч барлыкка килү вакыты өч елдан артып китсә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин